РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**29 июль 2024 ел** **№154**

2024 елга гражданнар керемнәренең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәтләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең чик кыйммәтләрен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү методикасы», «2024 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2024 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2023 елның 11 декабрендәге 888/пр номерлы боерыгы, «Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе нормативын билгеләү методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 18 августындагы 584/пр номерлы боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьяларына таянып, ТР Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик кыйммәтләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек бәясе чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 764 178,12 сум.

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 528 356,24 сум.

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 292 534,36 сум.

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 056 712,48 сум.

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 3 820 890,6 сум.

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 4 585 068,72 сум.

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 349 246,84 сум.

1.1.8. сигез кешедән торган гаилә өчен – 6 113 424,96 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык гомуми керемнең чик кыйммәте күләме, исәп-хисап буенча (1 нче кушымта) 14 900,41 сум тәшкил итә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (www.kukmor.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче В.Н. Андреев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 29 июлендәге 154 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм 2024 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

**1. социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннар сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба – исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:**

**СЖ= НП*РС* РЦ, монда**

СЖ – социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

НП – әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ – әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган торак урын мәйданының бер квадрат метрының Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга кире кайтарылмый торган субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый торган уртача базар хисабы бәясе.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ= 42454,34*18= 764 178,12 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ=42454,34*36= 1 528 356,24 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ=42454,34*18*3= 2 292 534,36 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ=42454,34*18*4= 3 056 712,48 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ=42454,34*18*5= 3 820 890,6 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ=42454,34*18*6= 4 585 068,72 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ=42454,34*18*7= 5 349 246,84 сум

з) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ=42454,34*18*8= 6 113 424,96 сум

**2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керемнең чик кыйммәте: ПД=0,7*СЖ*ПС/ {1-[(1+ПС) $^{-КП}$]}/ (0,3*РС), монда**

ПД – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм агымдагы шартларда түбәндәге формула буенча исәпләнә торган СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак бина сатып алу өчен банктан ипотека кредиты алу өчен кирәк булган уртача айлык гомуми керемнең чик күрсәткече;

СЖ – социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС – айлык кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма); (Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы елына 8,96%, ягъни айга 8,96/100/12 = айга 0,0075);

КП – кредитның бөтен срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 – кредит буенча түләүнең гаиләнең гомуми айлык кереме белән нисбәте.

«Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр союзы» НПның «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2024 елның 05 февралендәге 51 номерлы хаты нигезендә 2024 елда Кукмара

муниципаль районы Кукмара шәһәре буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 42454,34 сум тәшкил итә.

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь кыйммәтен исәпләү исәп-хисап буенча (1 нче кушымта) түбәндәгечә:**

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД=(0,7*764 178,12*0,0075) / {1-[ $(1+0,0075)^{-304.8}$]}/ (0,3*1) = 14 900,41 сум.

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7* 1 528 356,24 *0,0075) / {1-[$(1+0,0075)^{-304.8}$]}/ (0,3*2) = 29 800,82 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*2 292 534,36*0,0075)/ {1-[$(1+0,0075)^{-304.8}$]}/ (0,3*3) = 44 701,23 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*3 056 712,48*0,0075) / {1-[$(1+0,0075)^{-304.8}$]}/ (0,3*4) = 59 601,64 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*3 820 890,6*0,0075)/ {1-[$(1+0,0075)^{-304.8}$]}/ (0,3*5) = 74 502,05 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*4 585 068,72*0,0075)/ {1-[$(1+0,0075)^{-304.8}$]}/ (0,3*6) = 89 402,46 сум

ж) жиде кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*5 349 246,84*0,0075)/ {1-[$(1+0,0075)^{-304.8}$]}/ (0,3*7) = 104 302,87 сум

з) сигез кешедән торган гаиләгә:

ПД=(0,7*6 113 424,96*0,0075)/ {1-[$(1+0,0075)^{-304.8}$]}/ (0,3*8) = 119 203,28 сум